| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2021 г.Зеленодольск № 75

Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр тапшыру, һәм керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. 2021 елның 30 июненә кадәр (кертеп) «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче гражданнар, Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнар үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2014 елның 5 ноябрендәге 460 номерлы карары белән (2015 елның 10 июлендәге 546 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырырга бурычлы,

муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль учреждение җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче гражданнар Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында » 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасында бирелүче белешмәләр белән бергә, «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указына 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча, үзләренә, аларның хатынына һәм балигъ булмаган балаларына бер үк вакытта цифрлы финанс активларын һәм башка цифрлы хокукларны, утилитар цифрлы хокукларны һәм цифрлы хокукларны (булган очракта) үз эченә алган цифрлы финанс активлары турында хәбәрнамәләр тапшыра, дип билгеләргә.

2. 2014 елның 5 ноябрендәге 460 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән (2015 елның 10 июлендәге 546 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә 6 пунктның «в» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), хисап чорында цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында.»;

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 20 сентябрендәге 226 номерлы карары белән расланган, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында

белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә, 3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) шул акча исәбенә җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алуга килешү башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында, әгәр килешүләрнең гомуми суммасы килешү башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм шул акча исәбенә килешү башкарылган акчалар алу чыганаклары хакында белешмәләр ».

4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2012 елның 31 августындагы 185 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2013 елның 13 июнендәге 282 номерлы һәм 2015 елның 10 июлендәге 548 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә, 2 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) шул акча исәбенә җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алуга килешү башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында, әгәр килешүләрнең гомуми суммасы килешү башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм шул акча исәбенә килешү башкарылган акчалар алу чыганаклары хакында белешмәләр ».

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Совет рәисе** **М. П. Афанасьев**